# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 27 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» 2023 елның 13 июнендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:
«$5^1$. Конституция советы Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларына аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүенә мониторинг үткәрә, аның нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына мәгълүмат җибәрә.»;

2) 11 статьяда:
а) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Татарстан Республикасы норматив хокукый актының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы норматив хокукый актының йә аларның аерым нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүе яисә туры килмәве турында Конституция советы бәяләмәсендә хокукый җайга салудагы җитешсезлекне бетерү зарурлыгы хакында тәкъдим, шулай ук хокукый җайга салуны яисә хокук куллану тәҗрибәсен камилләштерү тәкъдиме булырга мөмкин.»;
б) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7. Татарстан Республикасы норматив хокукый актын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы норматив хокукый актын яисә аларның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы

Конституциясенә туры килми дип таныган, йә хокукый җайга салудагы җитешсезлекне бетерү зарурлыгы булган, йә хокукый җайга салуны яисә хокук куллану тәҗрибәсен камилләштерү тәкъдимнәре бирелгән Конституция советы бәяләмәсе бу норматив хокукый актны кабул иткән (чыгарган) орган (вазыйфаи зат) тарафыннан мәҗбүри каралырга, Конституция советы бәяләмәсен алган көннән алып өч ай эчендә Конституция советына һәм Татарстан Республикасы Рәисенә аны карау нәтиҗәләре турында хәбәр ителергә тиеш. Конституция советы бәяләмәсендә башка Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына, вазыйфаи затларга карата хокукый җайга салуны яисә хокук куллану тәҗрибәсен камилләштерү тәкъдимнәре булган мондый органнар, вазыйфаи затлар Конституция советы бәяләмәсен алган көннән алып өч ай эчендә шулай ук Конституция советына һәм Татарстан Республикасы Рәисенә әлеге тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру мөмкинлеге хакында хәбәр итәргә тиеш.»;

3) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. **Конституция советы эшчәнлеге турында доклад**

Конституция советы елга бер тапкыр Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына үз эшчәнлеге турында доклад җибәрә. Доклад Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Конституция советы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 11 декабрь
№ 84-ТРЗ